РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 елның 15 сентябре № 37

Түбән Кама шәһәр Советының 2012 елның 20 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре Уставы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2012 елның 20 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәр Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяның 2 өлешенә «Түбән Кама шәһәр Советының яңа чакырылыш эшли башлаган көненнән» сүзләрен «яңа чакырылыш Түбән Кама шәһәр Советының беренче утырышы хокуклы составта узган көннән» сүзләренә алмаштырырга;

3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Депутатның вәкаләтләре «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.И. Беляев